ГЛАВА
МАЛЬБАГУШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Нефтяников, д30, с.Мальбагуш,
Азнакаевский муниципальный район 423330

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МЭЛБАГЫШ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ

Нефтяниклар ур., 30 нче йорт, Мэлбагыш
авылы, Азнакай муниципаль районы, 423330

Тел./факс(885592)3-77-90,3-77-91; E-mail:Malb.Azn@tatar.ru,

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» ноябрь 2019 ел № 3

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең Мәлбагыш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 13 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә:Җәлил урамы 1 йорттан 58 а йортка кадәр, Нефтяниклар урамы 1 йоттан 62 йортка кадәр,Кооператив урамы 1 йорттан 10 йортка кадәр.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 13 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә: Колхозчылар урамы 1 йорттан 16 йортка кадәр, Комсомол урамы 1 йорттан 57 йортка кадәр, Мәллә урамы 1 йорттан 6 йортка кадәр, Нариман урамы 1 йорттан 63 йортка кадәр.

3.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенының беренче этабын уздыру вакыты – 13 ноябрь 2019 ел 10.00 сәг.тән 11.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты – 13 ноябрь 2019 ел 13.00 сәг.тән 14.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын уздыру урыны – Мәлбагыш авылы, Җәлил ур. , 4 йорт, Мәлбагыш авыл мәдәният йорты залы;

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 7 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Мәлбагыш авылы, Нефтяниклар урамы, 30 йорт
- сайлау хокукына ия булган Мәлбагыш торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;
- Мәлбагыш торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Мәлбагыш авылының Комсомол урамында юлларга таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш түяү)
- Мәлбагыш авылында юлларны кардан чистарту;
- Мәлбагыш кый авылында җәйге вакытта үлән чаптыру, территорияне җыештыру хезмәтләре;
- бүләк, сувенир продукциясе сатып алу, «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Халыкара инвалидлар көне», «Яңа ел», «Җиңү Көне " бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү;»

« РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес

буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Мәлбагыш авылында Нефтьчеләр урамы 30 йорт (Башкарма комитетның административ бинасы) ; Мәлбагыш авылы, Җәлил урамы, 2 йорт (авыл мәдәният йорты; Түбән Якый авылы, Кашапов урамы, 23 йорт ( ФАП ); Каменка авылында Җәлил урамы, 1 йорт мәгълъмат стендларында

3. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: И.Ә.Әхтәмова